

2023 ел Мордовия Республикасында Халыклар бердәмлеге елы дип игълан ителде. Шуна кvрә мәдәният учреждениеләре vткәргән кvп кенә чаралар шушы датага багышланган.
Тобәк лидеры Артём Алексеевич Здунов vзенен Мордовия Дәvләт Жыелышына Юлламасында бvгенге шартларда җәмгыятьнен традицион рухи-әхлакый кыйммәтләр нигезендә туплануы аеруча әһәмиятле булуын ассызыклады. Мордовиядә 60тан артык мәдәни чара vткәрv апрель аенда рәсми старт бирелгән Халыклар бердәмлеге елы кысаларында планлаштырыла. Алар арасында торле фестивальләр, форумнар, конкурслар, бәйрәмнәр һәм акцияләр бар. Аларнын кайберләре Пушкин картасы буенча vткәрелә.     Пушкин картасы тарихы 2021 елда башлана. Россия Президенты Владимир Владимирович Путин, Мәдәният министрлыгы һәм Цифрлы vсеш министрлыгынын уртак инициативасы белән яшьләргә аккредитацияләнгән кvргәзмәләргә, концертларга, музейларга, кинотеатрларга дотация нигезендә барырга момкинлек бирvче проект эшли башлый. Программаны техник яктан гамәлгә ашыру «Почта-Банк»ка йокләнгән. Анын бvлекчәләре хәтта Россиянен ерак почмакларында да бар. Остәмә рәвештә «Дәvләт хезмәтләре. Мәдәният» («Госуслуги. Культура») махсус кушымтасы эшләнде.




Пушкин картасы 14 яшьтән 22 яшькә кадәрге яшьләргә дәvләттән мәдәни чараларга йорv очен бvлеп би-релгән акчаны алырга момкинлек бирә. Проектнын стартында, 2021 елда, карта лимиты 3000 сум булса, 2022 елдан Пушкин картасынын номиналы бер елга 5000 сум тәшкил итә.
Мордовия Рес-публикасынын А.С.Пушкин исе-мендәге Милли китапханәсе, Россиянен барлык мә-дәният учреждениеләре кебек vк, Пушкин картасы буенча чаралар vткәрә. Шулай, 15 майда китапханәдә чираттагы чараны милли һәм туган якны ойрәнv әдәбияты бvлеге Мордовия халыкларынын тату гаиләсендә яшәvче кvпсанлы халыкларнын берсенә - татарларга багышлады. Николай Платонович Огарев исемендәге Мордовия дәvләт университетынын югары уку йортынында әзерлек факультеты студентлары очен татар милли ризыгын чәк-чәкне әзерләv буенча мастер-класс vткәрелде. Чаранын максаты – студентларны татар халкынын тарихы, мәдәнияте, гореф-гадәтләре һәм йолалары, милли ризыклары белән таныштыру. Монын очен «Мордовия татарлары» дигән китап кvргәзмәсен һәм Мордовия татарларынын кондәлек һәм бәйрәм ризыклары

турында презентация әзерләдек. Интернетта чәк – чәк әзерләv буенча мастер-класс видеосы кvрсәтелде. Бvлек баш китапханәчесе Әльфия Маланьчева ойдә чәк-чәк әзерләп алып килеп, чара тәмамлангач, татлы ризык белән чәй эчv оештырылган иде.

**Эльфия МАЛАНЬЧЕВА**, *Мордовия Республикасы А.С.Пушкин исемендэге Милли китапханэнен милли һэм туган якны өйрэнv эдэбияты бvлегенен баш китапханэчесе*